**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

20.10.2016 № 03-124

Казан ш.

Килешүнең типовой формасын раслау турында

“Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 12.10.2016 ел, № 735 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучы белән Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче арасында килешүнең типовой формасын (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министрның беренче урынбасары М.Д.Фәйзерахманов

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының
20.11.2016 ел, № 03-124
боерыгы белән расланды

**Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алучы арасында килешүнең**
**Типовой формасы**

___________________ш. «____» _________________ 20__ел

(килешүне төзү датасы)

_____________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче атамасы)

алга таба – «Вәкаләтле орган ______________________йөзендә,

(җитәкче яки вәкаләтле затының вазыйфасы атамасы)

_____________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

нигезендә эш итә ______________________________________________________,

(Хакимият органы турында нигезл., ышанычнамә, боерык яки башка док.)

бер яктан, һәм _____________________________________________________________,

(коммерциясез оешма атамасы)

алга таба – «Алучы», ________________________________йөзендә,

(Алучы исеменнән эш итүче зат атамасы)

_________________________, нигезендә эш итә ________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_____________________________________________________________________,

(Алучының гамәлгә кую документлары)

икенче яктан, алга таба – «Яклар», Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, “Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү

сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 12.10.2016 ел, № 735 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә, түбәндәгеләр турында бу Килешүне төзеде:

## I. Килешү предметы

1.1. Бу Килешүнең предметы булып 20__ елда бюджет классификациясе кодлары буенча ________________________________га
(Алучы атамасы)

гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тора:
кисәк ___________________________,
бүлек ___________________________,
бүлекчә ______________________,
максатчан статья __________________,
чыгымнар төре ___________________.

## II. Субсидия күләме

2.1. Бу Килешү нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидия күләме
____________________________ (________________________________) сум
(сумманы сүзләр белән күрсәтергә)
тәшкил итә.

2.2. Бу килешү нигезендә бирелә торган субсидия күләме Тәртипнең 11 пункты нигезендә билгеләнгән.

## III. Субсидия бирү шартлары

3.1. Субсидия түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

3.1.1. Алучының Тәртиптә билгеләнгән чикләүләргә туры килүе, шул исәптән:

3.1.1.1. Алучы Тәртиптә билгеләнгән сайлап алу критерийләренә туры килә;

3.1.1.2. Алучы чит илнең юридик заты булып тормый, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланыла торган салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен башкаруда мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмаучы дәүләт яки территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория (оффшор

зоналар) булып торган чит илнең юридик затларының катнашы җәмгысе 50 проценттан артып китми;

3.1.1.3. Алучының Субсидия бирү турында карар кабул итү датасына юк:

а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычы;

б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, түләү срогы чыккан бурыч, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары алдында түләү срогы чыккан башка төрле бурыч;

3.1.1.4. Алучыга бу Килешүнең 1.1. пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив-хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан средстволар бирелмәгән;

3.1.1.5. Алучыга карата бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законы нигезендә бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында эш кузгатылмаган;

3.1.1.6. Алучы үзгәртеп оештырылу, юкка чыгарылу процессында тормый, аңа карата хуҗалык эшчәнлеген алып баруга чикләүләр юк;

3.1.2. финанс ягыннан тәэмин итүгә Тәртип нигезендә Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешенең билгеләнеше;

3.1.3. Субсидия средстволары хисабына чит ил валютасын сатып алуга тыюның билгеләнүе, Россия Федерациясе законында билгеләнгән очраклардан тыш.

3.2. бу Килешүне төзегәндә, Алучы Тәртиптә һәм бу Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүгә ризалыгын бирә.

## IV. Субсидияне күчерү тәртибе

4.1. Субсидияне күчерү, Вәкаләтле орган тарафыннан, Алучының кредит оешмасында ачылган расчет счетына, бу Килешү төзелгәннән соң 20 көн эчендә хәл ителә.

## V. Якларның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Вәкаләтле орган үз өстенә ала:

5.1.2. Алучы Тәртиптә һәм бу Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартларын үтәгәндә, Алучыга Субсидия бирүне;

5.1.3. бу Килешүгә №1 кушымта нигезендә, гомуми белем бирү оешмасы базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткечләре) билгеләүне һәм нәтиҗәгә ирешүне бәяләүне;

5.1.4. Алучы тарафыннан Субсидия бирү шартларының үтәлешенә контрольлек итүне;

5.1.5. Алучыга Субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында таләпне җибәрүне:

Субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру, Субсидия бирүдә билгеләнгән башка шартларны бозу очрагында – тулы күләмендә;

Субсидиядән файдалану турында хисап тапшырмаган, хисапны вакытында тапшырмаган очракта – тулы күләмендә;

Субсидия средстволарыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан файдаланылмаган средстволар күләмендә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләре арасыннан ирешелмәгән һәркайсы өчен бер процент күләмендә;

5.1.6. Алучы бу Килешүнең 5.3.8. и 5.3.9. пунктларында күрсәтелгән Субсидияне кире кайтару срокларын бозган очракта, Субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган җиде көн эчендә, законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге средстволарны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрүне;

5.1.7. Субсидия алучы тарафыннан Субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне.

5.2. Вәкаләтле орган хокуклы:

5.2.1. Алучыдан Субсидия бирү шартларының үтәлешенә контрольлекне хәл итү өчен кирәкле документлар һәм материаллар соратып алуга.

5.3. Алучы үз өстенә ала:

5.3.1. бу тәртиптә һәм бу Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартларының үтәлешен тәэмин итүне, шул исәптән:

а) Субсидия средстволарын Тәртиптә күрсәтелгән чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә җибәрүне;

б) Субсидия средстволарына чит ил валютасын сатып алмауны, Россия Федерациясе законында билгеләнгән очраклардан тыш;

5.3.2. средстволарны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча Вәкаләтле орган таләпләрен бу Тәртиптә һәм бу Килешүдә билгеләнгән очракларда һәм срокларда үтәүне тәэмин итүне;

5.3.3. бу Килешүгә № 1 кушымтада билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итүне;

5.3.4. Вәкаләтле органга чыгымнар турында хисап тапшыруны, бу Килешүгә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, ________________ дан соңга калмыйча хәл итүне;
(число, ай, ел)

5.3.6. Вәкаләтле органга нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшыруны, бу Килешүгә №3 кушыта нигезендә, __________________________ дан соңга калмыйча тәэмин итүне.
(число, ай,, ел)

5.3.7. Вәкаләтле органга тиешле язмача извещение җибәрү юлы белән хәбәр итүне:

а) түләү реквизитлары үзгәрү очрагында – 3 (өч) эш көне эчендә;

б) 20__ елда Субсидиягә (Субсидия калдыгына) ихтыяҗның туктатылуы (булмавы) турында карар кабул итү датасыннан 5 (биш) эш көне эчендә;

5.3.8. алынган Субсидиягә (Субсидия калдыгына) ихтыяҗның булмавын дәлилләүче хәлләр килеп туганда, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр хисап финанс елында файдаланылмаган Субсидия средстволарын (Субсидия калдыкларын) Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерүне;

5.3.9. Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көн эчендә Субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны хәл итүне:

Субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру, Субсидия бирүдә билгеләнгән башка шартларны бозу очрагында – тулы күләмендә;

Субсидиядән файдалану турында хисап тапшырмаган, хисапны вакытында тапшырмаган очракта – тулы күләмендә;

Субсидия средстволарыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан файдаланылмаган средстволар күләмендә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләре арасыннан ирешелмәгән һәркайсы өчен бер процент күләмендә.

5.4. Алучы хокуклы:

5.4.1. бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар алу өчен Вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүгә.

## VI. Якларның җаваплылыгы

6.1. Яклар бу Килешү буенча үзләренең бурычларын үтәмәгәндә яки тиешенчә үтәмәгәндә Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Яклар арасында бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә килеп туган бәхәсләр, мөмкинлеккә карап, тиешле беркетмәләр яки башка документлар рәсмиләштерү нигезендә сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгән очракта Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

7.2. Бу Килешүне үзгәртү, Якларның инициативасы нигезендә, бу Килешүгә өстәмә килешү рәвешендә язмача рәвештә хәл ителә, ул Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имза салынганнан соң үз көченә керә.

7.3. Бу Килешүне Якларның үзара ризалыгы буенча өзәргә мөмкин.

7.4. Алучы Килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешә алмаган очракта бу Килешүне бер яклы тәртиптә өзәргә мөмкин.

7.5. Бу Килешү бер үк төрле юридик көчкә ия булучы ике нөсхәдә төзелгән, берсе – Вәкаләтле органга, берсе – Алучыга.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары

| | |
|---|---|
| Вәкаләтле орган атамасы | Алучы атамасы |
| Урнашу урыны:<br>(юридик адресы) | Урнашу урыны:<br>(юридик адресы) |
| Түләү реквизитлары: | Түләү реквизитлары: |
| | |

## IX. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Вәкаләтле орган атамасы | Алучы атамасы |
| _______________/ __________________<br>(имза) (ФИО) | _______________/ __________________<br>(имза) (ФИО) |

Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучы белән Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче арасында килешүгә №1 кушымта
«___»_______ 20____ел

20___ елда гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләрне кулланунын нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең пландагы зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Вәкаләтле орган

______________________
М.У.

Алучы

______________________
М.У.

Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучы белән Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче арасында килешүгә №2 кушымта
«___»_______ 20____ел

20___ елда гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләрне куллану турында хисап

Мең сум.

| Алучы атамасы | Агымдагы финанс елында алынган субсидия | Агымдагы финанс елында хисап датасына фактта тотылган субсидия | Хисап чоры ахырына субсидия калдыгы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Җитәкче

____________________ /_________________/
М.У.

Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алучы белән Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче арасында килешүгә №3 кушымта
«___»________ 20____ел

20___ елда гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль йөртергә өйрәтү сыйныфларын булдыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләрне куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең пландагы зурлыгы | Хисап датасына күрсәткечнең факттагы зурлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Җитәкче

____________________ /_________________/
М.У.